| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 28 декабрь г.Казань № 1235

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы дәүләт театр-тамаша мәдәният учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2023 ел, 7 сентябрь, 1094 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы дәүләт театр-тамаша мәдәният учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2023 ел, 7 сентябрь, 1094 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы дәүләт театр-тамаша мәдәният учреждениеләрендә спектакльләр (театраль куелышлар) күрсәтү (күрсәтүне оештыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарның һәм күләмнәренең 11, 12 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «11. | «Буа дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе | 1 910,69 | 8 800 | 2 110,69 | 8 800 | 2 015,08 | 4 400 |
| 12. | «Аяз Гыйләҗев исемендәге Яр Чаллы дәүләт татар драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе | 894,46 | 43 600 | 1 070,51 | 2 500 | 941,43 | 3 900»; |

әлеге карар белән расланган 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы дәүләт театр-тамаша мәдәният учреждениеләренең концерт программаларын күрсәтү

(күрсәтүне оештыру) буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарга һәм аларның күләмнәренә түбәндәге эчтәлекле 5, 6 пунктлар өстәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «5. | «Бермәнчек» керәшен дәүләт фольклор ансамбле» Татартан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе | - | - | 1 046,74 | 6 500 | 1 726,74 | 17 000 |
| 6. | «Агыйдел» дәүләт җыр һәм бию ансамбле» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе | 2 722,8 | 1 300 | 421,98 | 23 400 | 651,78 | 23 300»; |

әлеге карар белән расланган 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы дәүләт театр-тамаша мәдәният учреждениеләрендә спектакльләр әзерләү буенча эш башкаруга норматив чыгымнарның 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «11. | «Буа дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе | 1 868,2 | 2 063,8 | 985,2»; |

әлеге карар белән расланган 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы дәүләт театр-тамаша мәдәният учреждениеләрендә концертлар һәм концерт программалары әзерләү буенча эш башкаруга норматив чыгымнарга түбәндәге эчтәлекле 5, 6 пунктлар өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «5. | «Бермәнчек» керәшен дәүләт фольклор ансамбле» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе | - | 756,0 | 3 261,6 |
| 6. | «Агыйдел» дәүләт җыр һәм бию ансамбле» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе | 393,3 | 1 097,1 | 1 687,4»; |

әлеге карар белән расланган 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы дәүләт театр-тамаша мәдәният учреждениеләрендә спектакльләр күрсәтүне оештыру буенча эш башкаруга норматив чыгымнарның 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «11. | «Буа дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе | 6 380,7»; |

әлеге карар белән расланган 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы дәүләт театр-тамаша мәдәният учреждениеләрендә концертлар һәм концерт программаларын күрсәтүне оештыру буенча эш башкаруга норматив чыгымнарга түбәндәге эчтәлекле 5, 6 пунктлар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «5. | «Бермәнчек» керәшен дәүләт фольклор ансамбле» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе | 1 713,4 |
| 6. | «Агыйдел» дәүләт җыр һәм бию ансамбле» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе | 3 646,3»; |

әлеге карар белән расланган 2024 – 2026 елларга Татарстан Республикасы дәүләт театр-тамаша мәдәният учреждениеләренең билетларын сатудан керемнәр күләмнәренә түбәндәге эчтәлекле 20, 21 пунктлар өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «20. | «Бермәнчек» керәшен дәүләт фольклор ансамбле» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе | 628,0 |
| 21. | «Агыйдел» дәүләт җыр һәм бию ансамбле» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе | 1 145,0». |

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин